СӨЯ ГОМЕРНЕ, СӨЯ ХАЛЫКНЫ, СӨЯ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №70—71 (7243—7244) | 15 июнь, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

## План арттырып үтәлде

Бөгелмә ОРСның Норлат тимер юл станциясе коллективы агымдагы елның биш аенда 1178,1 мең сумлык товар реализацияләнде.

Планнарны үтәүдә «Радуга» кибетеннән сатучылар Миңния Абдуллина, Любовь Козлова, өлкән сатучы Любовь Фролова, икмәк кибетенең өлкән сатучысы Любовь Павлова, Гүзәл Вәлиәхмәтова, промышленность товарлары кибете сатучысы Валентина Пьянзина үзләреннән аеруча зур өлеш кертәләр. Алар ирешелгәннәр белән канәгатьләнмичә, яртыеллык планнарны тагын да арттырып үтәү өчен тырышлык куялар.

Л. ЕВСЕЕВА,
баш бухгалтер.

## „Үрнәк"тә үрнәк эшлиләр

Авыл эшчәннәре өчен мөһим кампания—печән әзерләү чоры житте.

Рифкать Әхмәтов, Касыйм Мөстәкыймов кебек уңганнарның эш сәгате иртә таңнан башлана, чөнки халыкта әйтелгәнчә, «чык барда чабып кал». Алар көнгә 20 шәр гектарда печән чабалар.

Чапкан печәнне тезем-нәргә салуда Рифкать Минеголов, әйләндереп киптерүдә Нәфис Шәфигуллин кебекләр эшләрен зур тырышлык куеп башкаралар.

## АВМ эштә

«Үрнәк» колхозында, печән чабу белән беррәттән, витаминлы үлән оны хәзерләүгә дә зур игътибар бирелә.

Касыйм Рәхмәтуллин КСК-100 комбайнында яшел массаны чаптыра, Рөстәм Мотыйгуллин АВМ-0,65 агрегатына ташып тора.

Ярдәмчесе Вәли Шиһапов белән берлектә Габдулла Шәйхиев вакыт белән санашмыйча агрегатның өзлексез эшләвен тәэмин итә.

Гомумән, хуҗалыкта хәзер бөтен көч терлекчелекнең нигезе булган мал азыгын мул әзерләүгә юнәлдерелгән.

И. ШӘЙХИЕВ,
экономист.

## Җәйләүләргә чыккач

«Татарстан» колхозының җәмәгать маллары урман буенда, табигатьнең иң гүзәл почмагында көтелә. Җәйге лагерьның биредә урнашуы савымчылар күңеленә аеруча хуш килә.

Иртә һәм кич ямьле аланны УДС аппаратларының салмак кына эшләгән тавышлары күмеп китә. Биредә мул сөт алу өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Маллар хәрәкәттәге яшел конвейердан өзелмиләр.

Тәҗрибәле сыер савучы Гөлчәчәк Насыйбуллина үз карамагындагы һәр сыердан уртача 14 килограмм сөт сава. Тәнзилә Нуруллина, Фәүзия Харламоваларның күрсәткече 13—13,5 килограмм.

З. ИСМӘГЫЙЛОВА.
«Татарстан» колхозы.

## Тырышлык куеп

**«Знамя Октября» колхозы.** Хуҗалыкның машина-трактор паркында бу көннәрдә эш тыгыз булды. Механизаторлар печән чапкыч агрегатларын көйләү эшләре белән мәшгуль булдылар. Биредә Владимир Нилович Лукоянов аеруча зур тырышлык куйды. Ул язгы чәчү чорында басуга ашлама ташып торган иде, эштә һич тә тоткарлык ясамады. Аның кебек уңган һәм булдыклы кешеләр тагын да бар. Герман Иванович Мензелеев Совет Армиясе сафларында яңа гына хезмәт итеп кайтса да, эшләгән эшенә тел-теш тидерерлек түгел. Аңар өр-яңа «Нива» комбайны бирелде.

Бензин ташый торган махсус машина шоферы Иван Александрович Мензелеев адресына да гел җылы сүзләр генә әйтергә була. Ягулык материаллары белән тәэмин итүдә моңарчы өзеклек булганы юк.

В. ИЛЬДИРЯКОВ.

## Иртәгә—Медицина работниклары көне



Таныш булыгыз: 94нче үзәк аптека провизор-аналитигы Зинаида Александровна Емельянова. Хезмәт вазифасы буенча ул үзәк аптекага буйсынган 6 аптекада да дару формаларына анализ үткәрә, аларга практик ярдәм күрсәтә. Башта фармацевтика училищесын, аннан Пермь фармацевтика институтын тәмамлаган грамоталы белгеч үз эшенә гаҗәеп җаваплы, таләпчән карый. Зинаида Александровна моннан тыш белешмә-информация әдәбиятын системалаштыру белән дә шөгыльләнә. Әгомумән алганда, биредә Емельянова башкармаган эш юк диярлек һәм теләсә кайсы участокта, теләсә нинди хезмәтне ул үзенә хас төгәллек, гаделлек, җыйнаклык белән алып бара.

## АРТКЫ ПЛАНГА КУЙМЫЙЧА

**«Рассвет» совхозы.** 70 гектар мәйдандагы бу җиргә узган елны терлекләргә ашату өчен арыш чәчелгән иде. Хәзер бу мәйданда яңадан дүрт ел буена күпьеллык үлән чәчеләчәк. Җиргә инде 50 тонна органик ашлама да кертелде. Аннан участокны ДТ-75 тракторларында Фәйзулла Бикинеев, Вәгыйзь Гайнуллин, Әсхәт Гафуров һәм К-701 тракторында Камил Габдуллин сөрделәр.

Шушы көннәрдә Фәйзулла Бикинеев чәчүгә төште. Аңа Нурсәлих Маняпов, Миннәхмәт Вильданов, Әсхәт Әхмәдиев, Шәмгун Маняпов булышалар. Шунысын да әйтергә кирәк, Миннәхмәт Вильданов һәм Шәмгун Маняпов, өлкән яшьтәге кешеләр булсалар да, эштә яшьләрдәй житез һәм өлгерләр.

Моңардан тыш өченче бүлекчәдә Хәниф Сөләйманович Фәйзуллин җитәкчелегендәге звено 150 гектар мәйдандагы бодай җирендә чүп үләннәренә каршы гербицидлар белән эшкәртү үткәрде. Хуҗалыкта печән чабу да арткы планга куелмый. Равил Галиев КС-2,1 чапкычында печән чабу эшләрен башкара.

170 гектар татлы тамыр плантацияләрендә исә Хәмит Харисович Низаметдинов җитәкчелегендәге аренда звеносы икенче катка рәт араларын эшкәртә башлады.

Хуҗалык әнә шулай бер эшне дә арткы планга куймаска тырыша.

В. САТДАРОВ,
экономист.

## „40 лет Победы" колхозыннан

### Кызу эш кайный

Илһам Гәрәевич Хафизов җитәкчелегендәге 11 кешелек аренда звеносы 100 гектар мәйданда татлы тамыр плантациясендә икенче катка рәт араларын эшкәртүгә кереште.

Звено узган ел да сынатмый эшләгән иде. Быел да зур тырышлык куеп, язгы чәчүне кыска срокларда төгәлләделәр. Арендачылар әнә шулай фидакарьлек үрнәге күрсәтеп һәм уртак тырышлык белән эшләгәндә зур уңышларга ирешәчәкләренә шикләнмиләр.

Колхозга чөгендер сирәкләүдә товарлыклы-сөтчелек фермасы (7 гектар), мәктәп (40 гектар), урман промышленносте хуҗалыгы (10 гектар), товарлыклы-дуңгызчылык фермасы (5 гектар) һәм район үзәк больницасы 18 гектар), госстрах (10 гектар) хатын-кызлары да булыша.

### Печәнгә төштеләр

Хуҗалыкта печән җире 312 гектар мәйдан били. Бүгенге көнгә шуның 50 гектары чабылып бетте.

ЮМЗ-6 тракторчылары Рәшит Әхмәтов, Хатыйп Сәйфуллин КПС-5Г агрегаты һәм әйләнмә җыйгыч белән аны җыю эшләренә керештеләр.

И. ХӘНИЕВ,

## Комбайннар ремонтлана

Ульянов исемендәге колхозның машина-тракторлар паркында да механизаторлар вакыт белән исәпләшмичә, икеләтә энергия куеп эшлиләр.

Комбайнчылар Варис Низамов, Миннәхмәт Фәйзуллин, Насыйх Бакиров комбайннарны 10 июльгә ремонтлап бетерү өчен зур тырышлык куялар. Алар кирәк җирләрдә детальләрне алмаштыралар, эретеп-ябыштыралар, майлыйлар һәм герметиклаштыралар.

А. ДАУТОВА.

● КЫРДА БЕРЕНЧЕ КӨННӘРЕ

## Болында—хезмәт шавы

ЮМЗ-6 тракторы көпчәк тиңентен үскән үләнне КС-2,1 агрегаты белән тигез тезем-нәр ясап чабып килде дә, ызан башында туктап калды.

Җиңел гәүдәле, уртача яшьләрендәге ир кеше кабинадан сикереп төшкәч, саф һаваны күкрәген тутырып сулап калырга теләгәндәй, беразга гына тынып калды да әйләнә-тирәгә күз йөртеп алды. Урман буендагы аланда аңардан башка тагын ике трактор печән чабалар иде.

Хезмәтнең гадәти бер җәйге көне иде бу: һәммә кеше үз эше белән янып яши торган чак. Әлеге тракторчы Хәлим Хаҗипович Фәйзуллин да печәнне оптималь срокларда чабып бетерү өчен тырыша. Тик тырышлыгы гына бушка китмәсен, әнә болытлар да куера башлады. Бер килеп явып киткән яңгырның никадәр көч куеп башкарылган эшне бер минутта юк итүе ихтимал. Дөрес, баштагы мәлне яңгыр теләделәр, ә хәзергә... Кирәкми иде дә бит. Ләкин ничек кенә булмасын, көн аяз торганда берәүнең дә басуны ташлап китәсе килмәс. 50 гектар мәйдан биләгән печән басуын алар—Ибраһим Фәйзуллин, Равил Хәнәфиев һәм Ришат Сәйфуллин өч-дүрт көндә чабып бетерергә исәплиләр.

Ришатка бераз кыенлык килеп чыкты менә. Шатуны сыну сәбәпле кырдан кайтып китәргә мәҗбүр булды. Хәзер инде инженерга кызу печән өстендә шатун артыннан йөрергә туры киләчәк. Запас частьләрнең җитешмәве белән XXI партсъездлылар да интегәләр: я печән чапкыч агрегатының урагы юк, я терсәк валы, заклепка, каеш кирәк. Ремонт-техника предприятиесе бу яктан әлегә әз ярдәм күрсәтә.

Нинди ватылулар булса да, аңардан чыгу юлларын эзләп табалар тагын. Бары тик эш кенә туктап тормасын. Ә хәзер печәнне чабып бетерергә һәм җыяргга кирәк. Шуңа да вакыт белән исәпләшмичә эшлиләрбиредә.

Г. РӘХИМОВА.

**Бөек Ватан сугышы башлануга 50 ел тулуга карата**

# Бәхет эзләгәндә

## 1. Күченүчеләр

1939 елның 30 ноябрендә башланган фин сугышы 1940 елның 12 мартында тәмамланды. Аның безнең армия өчен нинди кыен шартларда баруы, рәхимсез салкында күпме сугышчының туңуы, зур югалтулар, бу сугышта җиңүнең безгә нинди бәһага төшүе турында—ниһаять, 50 еллап вакыт үткәч— хакыйкатьне, бу кампаниягә карата объектив бәяне ишетә алдык. Әмма бүген, Бөек Ватан сугышы башлануга 50 ел тулган көннәрдә максатым ул түгел, бөтенләй башка. Крестьян һәм аның җир, бәхетле тормышка омтылышы, чәлпәрәмә килгән хыяллары турында.

Бу хәрби конфликттан соң, тарихи язмаларда мәгълүм булганча, чик яңадан карала, Фин култыгының бер өлеше, Выборг шәһәре һәм аның янындагы территорияләр Финляндиядән СССРга күчә. Җирле халык, торак йортларын, хуҗалык корылмаларын калдырып, бу урыннардан китеп барды.

Хөкүмәт чик буен ныгыту, ныклы тыл булдыру һәм, әлбәттә, бушап калган яңа җирләрне үзләштерүне күздә тотып чаралар күрә. Илебезнең халык тыгыз урнашкан районнарыннан яңа җиргә күчереп урнаштыру турында карар чыгара. Халыкны оешкан төстә күчерү бүлеге вәкилләре яңа җирдә тормышны мул, иркен тасвир итәләр, шуңа күрә теләүчеләр күп табыла. Килешү буенча күченүчеләр арасында Кәкре Атау, Чулпан, Якты Күл, Әхмәт кебек төрле авыл крестьяннары бар иде. Биккол авылыннан күченүчеләр арасында ун, шул исәптән безнең гаилә дә бар иде.

Ул чактагы күченүне, 6 яшьлек малай гына булсам да, яхшы хәтерлим. Җәй башы иде. Безне Норлат шәһәрендә формалаштырылган составка төяделәр. Ул тулысы белән товар вагоннарыннан гына тора иде. Ул вагоннарда кем ничек булдыра ала шулай урнашты. Туклану мәсьәләсендә дә шул ук принцип хәрәкәттә иде: алдан хәзерләнгән коры ризыкка мөмкин булганда станцияләрдә әти-әниләр өстәмә ашамлык ала килделәр.

Үзебез белән янәшә вагоннарда мал-мөлкәтебез һәм терлек-туар барды. Һәркем булдыра алган кадәрен: кашык-савыт, кием-салым, сандык, иске шкаф кебек бөтен әйберен тутырган иде. Малның да ниндие генә юк—мөгезле терлектән башлап эт һәм мәче баласына кадәр үзе белән алган иде якташларыбыз. Без дә яңа җиргә гомерлеккә диеп юлга чыккан идек.

Шундый шартларда булса да, өлкәннәрнең күңеле күтәренке иде. Бу безгә дә йокты. 20 көнләп шулай барып, печән өстендә Выборг станциясенә килеп җиттек. Анда безне пар атлар җигелгән фургоннарга төяп, торачак йортларга алып киттеләр. Беренче торак янына килеп туктагач, йортның тәрәзәләре ватык, ташландык икәнен күреп,эти алып килгән әйберләребезне бушатудан баш тартты.

Безнең гаилә, ахыр чиктә, Выборгтан алты, үзәк юлдан бер километрлар читтә корылган йортка төпләнде. Шунысы характерлы, анда бездәге шикелле бергә тупланып яшәү юк, өйләр берсеннән-берсе 1,5—2 чакрым ераклыкта хутор тибында урнашкан.

Халыкны урнаштыру белән хәрбиләр шөгыльләнде. Аннан соң килгән халык бергә җыелып «Алга» колхозы оештырды. Аның рәисе итеп Исмәгыйль Ибраһимов сайланды. Әти Хуҗиәхмәт Сәлахов, Касыйм Гайфуллин, Минәхмәт һәм Миннехан Галимовлар, Вәли Кыямов һәм башка күп агайлар белән шул колхозда эшләп йөрде. Әни йорт мәшәкатьләре белән булышты, без, укырга кермәгән балачага, йорт тирә-юнендә уйнап йөрдек. Яңа җирдә тормыш эзенә төште шикелле.

Кыш үтеп китте. Безгә якын урманнарга яңа хәрби частьләр килә башлады. Алар ачыктан-ачык китерелмәгән күрәсең,мин, алар нинди дер фильм төшерүдә катнашалар, дигәнне хәтерлим. Безгә, кызыксынучан малайларга алар янына якын бару рөхсәт ителмәде. Торабара безгә караңгы төшкәч тирә-күршеләребез янына барып йөрү дә тыелды.

1941 елның 21 июне җитте. Кич якынлашканда әти безне—әнине, мине, яшь ярымлык энемне һәм күршеләрнең гаиләсен шәһәргә илтте һәм вокзалда калдырды. Без туган якка кунакка кайтып килергә исәпләгән идек. Төгәл вакытын хәтерләмим, әмма Ленинградка поезд 22 июньдә бик иртә китәсе, ә аңа кадәр чиратта озак торасы булганга шулай алдагы көнне үк килтереп куйды эти. Пассажирлар күп иде, әни чиратка басты. Без көтү залында калдык. Мин йоклап киткәнмен...

Төнлә кешеләр шаулашуына һәм кычкыруына уянып киттем. Беренче мәлдә, йокыдан айнып җитмәгән килеш, берни чамалый алмый тордым: әйберләрен күтәргән, балаларын тоткан кешеләр ыгы-зыгы астында төрле якка йөгерешәләр. Күңелгә кергән курку хисеннән йокы качты, әни калган җиргә, билет кассасы янына ашыктым. Әни инда юк иде. Инстинкт буенча урамга йөгереп чыктым. Анда хәрбиләр күп, кулларына махсус тасмалар бәйләгән противогазлар аскан хатын-кызлар арлы-бирле йөренә. Күктә самолетлар гүләве ишетелә, күңелгә шик керә. Төн караңгылыгы, ялгыз калудан курку хисе ул шикне тагын да арттыра.

Мине, башкалар белән бергә, яңадан вокзалга кертеп җибәрделәр. Андагы халык арасыннан кабат туганнарымны, күршеләремне эзләп карадым, файдасы тимәде.

Соңыннан ачыкланды: мин йоклаганда «Һава тревогасы» сигналы буенча урамга агылган барлык пассажирларны бомбоубежищега куып керткәннәр. Мин шулай аерылып калганмын.

Озак эзләп, каңгырып йөргәннән соң вокзал мәйданына чыгу юлындагы диванга барып сыендым. Ул чактагы курку, билгесезлек хисе, кызганыч бер халәтемне язып аңлату авыр, үзең кичерергә кирәк. Алар 50 елдан соң да хәтеремдә ачык саклана.

Таң аткач, тынып калган вокзал мәйданына чыктым, коралды хәрбиләр торган күпер аша узып өебез ягына юл алдым. Күпер сакчылары мине тоткарламадылар. Аннан чыккач йөгерә үк башладым. Бәхеткә бер автомашина очрады, туктады. Аның кабинасыннан таныш офицер (ул якташ буларак эти янына өйгә килеп йөри торган абый) булып чыкты, чакырып алып, янына утыртты һәм безнең юл аермасына кадәр утыртып кайтты.

Өйдә ишек бикләмәгән, ләкин кеше юк иде. Курку катыш аптырау хәлендә хуторлар уртасында урнашкан авыл Советы бинасы янына киттем. Анда хатын-кызлар, балачага елаша иде. Сугыш башлануы, мобилизациялә баруы турында шунда ишеттем. Әтине мобилизация буенча шәһәрдәге җыелу пунктына алып китүләре билгеле булды.

Башка барыр урын булмагач, өметсезлеккә бирелгән хәлдә өйгә әйләнеп кайттым. Туйганчы тәгәрәп еладым. Шул килеш йоклап та китканмен. Кемдер мине төрткәләгәнгә күзләремне ачып җибәрсәм, алдымда ике милиционер һәм әни елап тора иде...

## 2. Качаклар

Икенче көнне без этине күрү өчен җыелу пунктына бардык. Анда халык, шул исәптән хәрбиләр дә күп, тик аның кая икәнен белүчесе юк: күрә алмый кайттык.

Без яшәгән территория беренче көннән үк сугыш алды зонасына әверелде. Әмма ул вакытта үзебезнең туган якка кире кайтырга рөхсәт итмәделәр, озакламый оешкан төстә эвакуацияләү үткәрелә дигән хәбәр тараттылар. Билгесезлек шартларында яши бирдек: терлек көттек, көн аралаш шәһәргә сөт сатарга бара, аның акчасына ипи ала идек.

Июль уртасына хәл кискен үзгәрде: яктылыкны мәҗбүри маскировкалау кертелде, туплар гөрселдәгән тавыш ишетелә башлады. Ул торган саен озаграк һәм көчлерәк яңгырады. Халык куркуга төште, кайту өчен әйберләрен җыя, төрә бирде.

Бер көнне кич безнең өйгә хәрби киемнән, винтовка белән коралланган Хуҗиәхмәт абый Сәлахов килеп керде. Янында үзе ише ике юлдашы да бар иде. Ул безнекеләрнең чигенүен, фронт линиясенең якында гына узуын хәбәр итте. Ул безгә җыенырга нибары бер сәгать вакыт бирде, үзе шул арада авыл Советына документлар һәм олау артыннан барып килде.

Билгеләнгән вакытка кашык-савыт һәм башка иң беренче кирәк әйберләр тутырган кәрзинкәләребезне һәм иске-москы салынган капчыкны олауга салдык та киттек. Терлек, кошкорт йортта, мал-милкәт йозак астында өйдә калды. Безгә, алар соңрак эвакуацияләнә, Норлатта алырсыз, дип әйттеләр. Әмма, еллар үткәч, мал-милек түгел, үзебезнең исәнимин кайтып ирешә алганга сөенәм.

Станциягә килеп җиткәч, Хуҗиәхмәт абзый берничә минуттан шәһәрдән эвакуацияләнгән халыкны төягән эшелон китәсен, тик анда инде урын юклыгын ачыклады. Солдат югалып калмады, рөхсәтсез-нисез бер вагон ишеген ачты, өлкәннәрне этеп-төртеп кертеп җибәрде, мине исә, кулымдагы теге кәрзин белән икенче кат нарга ук китереп утыртты. Ниндидер бер хатын-кыз янында булып чыктым. Ул мине этә, тиргәнә башлады: елап җибәрдем. Шуннан соң гына йомшады. Бу 20 июльдән 21 енә каршы төндә булды.

Иртән без иске чик буена барып җиттек. Анда без икенче составка күчеп утырырга тиеш идек.Моның сәбәбе шунда ки, СССРда тимер юл линияләре Көнбатыштан аермалы, киңрәк, бер очтан утырып китә алмыйсың.

Вагоннардан төшә башладык. Кинәт эшелон өстендә ике немец, самолеты килеп чыкты һәм безнең өскә ниндидер металл әйберләр (мичкәләр, капчыклар һәм башкалар) ташларга керештеләр. Ул әйберләр төшкән чакта төрле куркыныч тавышлар чыгаралар, психикага тәэсир итәләр, паника тудыралар. Ул чакта, җиңүле марш белән атлаган вакытта, гитлерчылар корбаныннан бигрәк шунысын исәпкә алдылар, үзләре өчен мәзәк таптылар булса кирәк—шулай эшләделәр. Качаклар котлары алынып урманга йөгерәләр, самолетлар киткәч кенә состав янына җыела башлыйлар. Ул арада немец самолеты кабат килеп җитә. Бу уен шулай көне буе дәвам итте.

Төнлә, ниһаять, эвакуацияне оештыручыларга халыкны җыярга мөмкинлек туды. Ләкин, безгә мәгълүм булмаган сәбәпләр аркасында, эшелон китеп өлгерә алмады. Таң ату белән бөтенесе яңабаштан кабатланды. Ашау-эчү түгел, су турында да кайгыртучы булмады, һәркем бу тәмугтан исән чыгып ычкыну турында гына уйлады.

Өченче көнне безне Ленинградка китереп җиткерә алдылар. Тик составны шәһәргә кертмәделәр, чөнки очраган җирдә теләсә нинди су эчеп күбебез дизентерия белән чирле иде инде. Вокзал тирәсендә өч көн иза күреп яшәгәннән соң балачагасын ияртеган, төентаенын күтәргән хатын-кызны махсус составка урнаштырып төньякка алып киттеләр. Аннан әйләнгеч юл белән 4 августта Иваново шәһәренә кайтып җиттек. Бу ерак тыл иде, әзрәк сулыш алырга мөмкинлек туды. Без мунчада булдык,йогышлы авыруларга каршы уколлар ясадылар. Иң мөһиме, махсус паек алдык, күпме михнәтле юл үтеп беренче кайнар аш ашадык. Моңа өстәп безгә зур станцияләрдә туклану өчен талоннар дә бирделәр. Бу азмы-күпме пассажирларга карата кешечә мөнәсәбәт иде.

Аннан безне Сызраньга озаттылар. Анда күчеп утырудан соң Норлатка кайтып җиттек. 11 август көнендә туган авылыбыз Бикколда идек инде. Безнең белән бергә теге чакта Хуҗиәхмәт Сәлахов утыртып җибәргән гаиләләр тагын бар иде. Кайберләре чит авылдан булганга миңа таныш түгел иде. Алда язылган гаиләләрдән исә ул чакта Касыйм Гайфуллиннар гаиләсе кайтты.

Мин, михнәт күреп булса да, кайтып калуыбызны зур бәхеткә саныйм. Бездән соң Миңнеәхмәт Галимовның хатыны ялгыз кайтты, юл газабыннан балалары үлеп калды. Ачлыктан һәм йогышлы авырулардан балалары үлүчеләр арасында Вәли Кыямов гаиләсе һәм башкалар да бар иде. Кайтырга өлгермичә Ленинград блокадасында калучылар да булды, аларның язмышы бөтенләй билгесез **(сүз уңаеннан 1940 елда бәхет эзләп китүче ул гаиләләргә, аларның балаларына, туганнарына үзләре турында белдерүләрен сорап мөрәҗәгать итәм. Бәлки ул зонада калучылар белән элемтә тотучылар да бардыр. Күченүчеләр һәм качак якташларыбыз, сездән хәбәрләр көтеп калам. Минем адрес: Норлат шәһәре, Советская урамы, 123 йорт, 2 фатир. Телефон: 2—21—36. Минвәзир Идрисович Сираевны сорарга).**

Без кайтканда урак өсте, иң мөһиме, барысы тыныч иде. Юл михнәтләреннән соң туган якта, халык арасында ачлы-туклы яшәү дә җәннәт кебек тоелды. Шәрә йортка кайтып керсәк тә, ул үзебезнеке иде. Безнең ише бәхет эзләп йөрүчеләрнең бер ишесе йортын да саткан иде. Алар буш йортларга керделәр яисә өйдәш булып урнаштылар.

Дүрт елга якын сугышның башы гына иде әле бу. башы гына иде әле бу.Аның авырлыгын без дә башдек. Бер уңай ягы булды, безнең гаиләләр качаклар рәтенә кертелде, он, сирәк булса да ярма бирәләр иде. Ачтан үлүдән безне шул коткарып калды.

**М. СИРАЕВ.**

Норлат шәһәре.

---

## *Сез беләсезме?*

**БУЙ ДА ҮЗГӘРӘ ИКӘН**

Кешенең буе иртәнге сәгатьләрдә башка вакытлардагыдан озынрак була...

Сәбәбе болай аңлатыла. Төнге йокы вакытында тән озынлыгы якынча бер сантиметрга арта. Умыртка сөяге арасында урнашкан күзәнәкле дисклар бу вакытта организмнан килгән сыекча белән тула. Кешә торып баскач, дисклар кысылу аркасында бу сыекча кысрыклап чыгарыла һәм кешенең буе элекке хәленә кайта.

**ТЕЛ АЧКЫЧЫ ТАПКАННАР**

Сәгуд Гарәбстанынан 25 яшьлек бер кызны тумыштан ук чукрак-телсез дип исәпләгәннәр. Беркөнне кызны үзеннән ике тапкыр өлкәнрәк яшьтәге кешегә кияүгә бирмәкче булалар. Шунда кыз телгә килеп, «Туй турында сүз дә булуы мөмкин түгел, картлачка кияүгә чыкмыйм», дигән.

**КИЯҮДӘ БУЛМАСА ДА**

Брюссельдәге никах конторасы иң хисле мәхәббәт хатына конкурс игълан иткән. Җюри, бик күп хатларны тикшергәннән соң, Кристиан Маурены җиңүче дип тапкан. Хат авторы бүләкне алырга килгәч ачыклануынча, ул 78 яшькә җитеп бер генә тапкыр да кияүдә булмаган икән.

# МӘГЪЛҮМАТ

**Проблемалар. Сораулар. Яңалыклар.**

## 25 минутлык юл

**Германиядә әле яңа гына Урда Юргенсның «Раиса Горбачева» дигән китабы басылып чыкты. Укучыларны бу китап СССР Президенты һәм аның гаиләсенең ничек яшәүләре белән таныштыра. Шул китаптан өзек тәкъдим итәбез.**

Совет җитәкчелеге гадәтләреннән тайпылмыйча, Горбачевлар гаиләсе дә 1985 елдан бирле шәһәр читендәге дачада яши. Мәскәүдән 30—40 километр көнбатыштарак урнашкан шундый ук дачаларда хөкүмәт әгъзаларының күпчелеге тора. Бу дачаларга артык киң булмаган әйбәт шоссе юл алып бара. Ике яклап утыртылган агачлар юлга ниндидер романтик рух та өсти сыман. Бары берничә километр гына артта пычрак, бөркү, тынычсыз Мәскәүдер дип күз алдына да китереп булмый. Юлда хәрәкәт тә юк дәрәҗәсендә, онытканда бер генә автомобильләр җилдерткәли.

Һәр юнәлештә—бер хәрәкәт полосасы. Йөк машиналары бу юлга бөтенләй дә керми; нигездә—кара «Волга»лар, яки «Чайка»лар, сирәгрәк—«ЗИЛ»лар. Бу—югары хөкүмәт даирәсеннән кем дә булса килә дигән сүз. Совет хөкүмәтенең иң зур лимузиннарының берсе Политбюро әгъзаларын һәм ҮК секретарьларын йөртә. Бронялы лимузинда Горбачев яки аның гаиләсеннән кемдер булырга мөмкин.

Дөрес, Михаил Горбачев гадәттә тулы бер автоколонна озатуында йөри— иң алда куркынычсызлык хезмәте «Мерседес»ы, бер яки ике кара «Волга», ике «ЗИЛ» һәм «ЗИЛ-комби» —ашыгыч ярдәм машинасы, колоннаның койрыгында —тагын бер кара «Волга». Президентны һәм аның гаиләсен һәрдаим куркынычсызлык хезмәте офицерлары (җидедән алып унике кешегә чаклы) озатып йөри: группа җитәкчесе машина эчендә, калган тән сакчылары—кара «Волга»ларда.

Михаилның үзенә дә, Раиса Горбачевага да машинаны йөртергә рөхсәт итмиләр.

Кремльдән, Раиса Горбачева эшли торган Мәдәният фондыннан дачага кадәр 25 минутлык юл. Төп шоссedан тар гына асфальт юл галәмәт зур дачага алып килә. Әйтергә кирәк, хөкүмәт дачаларының барысының да коймалары бертөсле: бик биек, өстә ток җибәрелгән тимерчыбык. Авыр капканың тегe ягында—сакчылар йорты.

Генсекны һәм аның гаиләсен Куркынычсызлык комитеты офицерлары һәм хәрбиләр саклый. Бу тән сакчыларын ике төркемгә бүләргә мөмкин. Беренчесе, тышкы төркем дип әйтелә торганы, 12 кешедән тора һәм Горбачевны һәм аның хатынын һәрвакыт шәһәрләрдә, республикаларда, чит илләрдә йөргәндә саклый. Икенче төркем дачаны һәм шәһәрдәге фатирны каравыллый. Дачадагы сакчыларның саны «хуҗаның» өйдә булу-булмавына бәйле. Әгәр дә ул өйдә икән, сакны койманың тегe ягына да куялар. Дачаның бөтен территориясе буйлап, өйдән коймага хәтле,электр сигнализациясе үткәрелгән. Кем дә булса өйгә якын килеп, ялгыш кына кагылса, ул эшли башлый, шунда ук бу урынга сак этләре белән оператив группа килеп җитә.

Дача белән комендант идарә итә. Ул йорттагы сак өчен генә түгел, ә йортның һәм территориянең торышы өчен дә җаваплы. Гадәттә бу постны КГБның 9 нчы идарәсеннән профессиональ хәрбиләр били. Гомумән, калган барлык башка персонал да, пешекче, җыештыручы һәм бакчачыны да кертеп, барысы да хәрбиләр.

Капкадан өйгә тар гына аллея алып килә. Дачаның территориясе бик зур,аның иң күп өлеше катнаш урманнан тора, агачлардан күберәк чыршы һәм нарат өстенлек итә. Йорт алдында һәм артында елгага төшеп җиткәнче—чәчәклек. Бакчаның архитектурасын хуҗа хатын билгели. Горбачевлар бакчасында гладиолуслар, астра, тюльпаннар күп. Роза куаклары да бар, әмма алар Мәскәү климатында үзләрен бик үк әйбәт хис итмиләр.

Ел әйләнәсе дымлы җәй патшалык итүче оранжерея дә бар. Кыяр, помидор, кабак һәм башка яшелчәләр янына чәчәкләр дә «сыйган»: экзотик орхидеяләр, роза, канәфер, нәркис, крокуслар. Дача коймасы буеннан ук җиләк-җимеш бакчасы башлана, бакчада горур кыяфәттә тавис кошлары, фазан һәм мисыр тавыклары йөри.

Йортны урап чыккач, аның күзгә ташланмый торган галереялар аша башка биналар белән дә тоташканын күрәсең. Бу галереяларның берсе пыяла, һәм металлдан төзелгән бер катлы бинага алып керә. Монда—йөзү бассейны һәм сауна. Бассейнны уратып алган стеналар җәй көне автоматик рәвештә ачылалар һәм бассейн ачык һавада кала. Бассейн тирәсендә—үреп эшләнгән фин җиһазы, тирбәлмә урындыклар, җете төстәге мендәрле шезлонглар. Зәңгәрсу плитә белән эчләнгән бассейндагы суның төсен теләгәндә, кояшлы көндәге зәп-зәңгәр диңгез төсеннән алып, ярга кагучы давыл дулкыны төсенә кадәр үзгәртергә була.

Бассейннан саунага мәрмәр баскыч алып төшә: башта агач белән эчләнгән иркен бүлмәгә керәсең, калын ишек артында —сауна.

Икенче бер галерея хуҗалык блогына алып бара. Анда кухня, склад, персоналның ял бүлмәләре урнашкан.

Дача үзе—ике катлы бина. Эчке эшләрен һәм санитар-техник җиһазларга киткән чыгымнарны хисапламыйча, Горбачевның дачасын төзү алты миллион сумга төшкән. Бу суммага шулай ук вертолет төшерү мәйданчыгын, элемтә бинасын,кунакларга дип аталган йортны төзү дә керә.

Төп бинада якынча егерме бүлмә. Интерьерда, элеккечә үк, агач панельләр, күн белән тышланган саллы җиһазлар, калын пәрдәләр кулланыла.

Сталин вакытларындагы кебек үк, хәзер дә хөкүмәт дачалары өчен җиһазны Мәскәүнең «Люкс» фабрикасы эшли. Һәр дачаның коридорларында кыр-кырлары яшел буйлы, чия төсендәге келәм-сукмаклар—гадәти күренеш.

Идән имән паркет белән капланган. Бүлмәләрдә гөлләр күп. Россия өчен ят булган чәчәкләр үсә торган кышкы бакча да бар.

Гомумән алганда, Горбачевларның дачасы уңайлы, яхшы җиһазланган,әмма монда барыбер атмосфера салкынчарак, дип әйтер идем. Бу йортның гомер буе бер генә гаиләнеке булмавы, алар өчен бу бары тик хөкүмәт дачасы гына булуы сизелеп тора.

Бу зур хуҗалыкны алып бару һәм тәртиптә тоту өчен бик күп кеше кирәк, әлбәттә. Паркны тәрбияләп торучы бакчачылардан тыш, монда берничә пешекче һәм официант, техник персонал эшли. Пешекчеләр арасында ир-ат та, хатын-кызлар да бар, әмма шеф-повар — һәрвакыт бары тик ир кеше.

Эшкә урнашыр алдыннан һәрбер кандидат җентекләп тикшерелә, ә эшкә кабул ителгәннән соң кайда һәм кем булып эшләве турында хәзер дә, хезмәт килешүе өзелгәннән соң да беркемгә дә сөйләмәү турындагы кәгазьгә кул куя.

Горбачевлар гаиләсен азык-төлек белән хөкүмәт хисабыннан тәэмин итәләр. Горбачев Генсек булган сәгатьтән алып, җитәкчеләр өчен булган махсус кибеттән гаилә инде файдаланмый. Бөтен төр продуктка заказ бирелә һәм болар өйгә китерелә. Раиса Горбачева гаиләгә нәрсә ашату турындагы исемлекне үзе төзи. Шушы исемлекне ул атнага бер тапкыр диетологка күрсәтә. Ул төзегән менюны бары диетолог кына үзгәртә ала.

Дачада да, шәһәр фатирында да ризыкны КГБ күзәтчелегендә әзерлиләр. Барлык ризыкны да кабып карауччы махсус кеше бар. Аны «гөмбә кешесе» дип атыйлар, ягъни ризыкта агу-фәлән булса, беренче булып ул үлә. Раиса Горбачевага пешерергә рөхсәт ителми, чөнки теоретик яктан, ул ирен агуларга мөмкин дип исәпләнелә.

Ризыкны, әлбәттә, өйдә генә түгел, ә барган җирдә дә тикшерәләр. Хәтта туган авылы Привольноеда әнисенең Генсекка ашарга әзерләргә хакы юк. Продуктлар һәрдаим тикшерелеп тора. Пычрак, савыт-сабаны да өстәл әзерләгән сакчылар гына җыеп алырга тиеш.Икенчеләре, үз чиратында, ризыкны өстәлгә бирүне күзәтә.

## Әйләнеш—миллиард



**Ленинград өлкәсе кулланучылар кооперациясенең былтыргы әйләнеше миллиард сумнан артып китте. Дистәләгән миллион сум керем алынды. Авылда хәзер дефицит булган ысланган колбасадан алып «Геркулес» ярмасына кадәр чыгаручы, эшкәртүче предприятиеләр һәм цехлар төзелгән.**

**Гатчинск промкомбинаты өлкә кулланучылар кооперациясендә иң перспективалыларның берсе санала. Болар—терлекләр симертү фермасын, ит эшкәртү цехларын, әзер продукцияләрне сату өчен билгеләнгән кибетләрне үз эченә алган заманча комплекс. Кооператорлар Ленинградның промышленность предприятиеләре белән хезмәттәшлек килешүләре төзиләр.**

**Рәсемдә: технолог Светлана Брезгина.**

**ТАСС фотохроникасы.**

## „Сөяксез" кеше һәм башка могҗизалар

**Сезнең «Гиннесс рекордлары китабы» хакында ишеткәнегез бардыр инде. Һәм менә, ниһаять, безнең илебездә дә кызыклы рекордларны җыю һәм теркәү белән шөгыльләнүче агенство эшли башлады. Ул ПАРИ (Парадокслар, Рекордлар, Идеяләр сүзләреннән) исемен йөртә.**

**Австриядә һәм бер үк вакытта бездә «ПАРИның рекордлар китабы» басылып ята. Меңнән артык искиткеч факт теркәлгән анда. Алар 250 төсле иллюстрация белән бизәлгән. Нибары 100 мең тираж белән басылучы бу китап, мөгаен,предприятиеләрдән алынган заявкалар нигезендә таратылыр.**

**Ә хәзер әлеге китапка керергә өлгермәгән, ПАРИ агентлыгы шушы көннәрдә генә теркәгән кайбер рекордларга күз салыйк.**

**Таныш булыгыз!**

КЕШЕ-ХАМЕЛЕОН Валерий ЛАВРИНЕНКО— Донецк шәһәреннән. Тәненең кайбер өлешләрендә тиресенең төсен актан карага кадәр үзгәртә ала. Кызыл, яшел, сары төсләргә дә күчә. Цельсий буенча 100 градуслы суда йөзә. Су астында тын алмыйча 10 минут тора ала.

КАЛЫН ТИРЕЛЕ КЕШЕ— Нукри ГВИНИАШВИЛИ Тбилисидан. Ул кадаклар, сөнгеләр, пычаклар, пыяла өстендә ята. Корсагын үткен пычак белән сызгалый—яраның, канның әсәрен дә күрмәссең. Һәм тагын чәчең үрә торырлык әллә никадәр могҗизалар күрсәтә.

Михаил ЭРСТЕНЮК— СӨЯКСЕЗ КЕШЕ. Ул теләсә кайсы буынын үз оясыннан чыгара ала. Муенның 360 градуска бору, терсәген кирегә каратып «вату», беләзеген «күчәре» тирәсендә берничә кат борып әйләндерү дисеңме —берсе дә калмый.

Джембер ЛЕЖАВА— ГАҖӘЕП ИХТЫЯР КӨЧЕНӘ ХУҖА КЕШЕ: берничә ел элек кенә аңа инвалидлык бирәләр. Ашказанында рак башланып катлаулы операция кичерә ул. Ләкин Джембер бирешми: менә бүген, өч елдан соң,—инвалид—чемпион. Джумбер Лежава бер сәгать эчендә идәннән кулларына 5001 тапкыр күтәрелә ала.

Мәскәүле Сергей БОЙЧУК, әллә ни тырышлык куймыйча гына, чирек кубометрлы ПЫЯЛА ТАРТМАГА СЫЯ. Тартма стеналарының калынлыгы—12 миллиметр.

Тагын бер сәер рекорд —Львовның шәһәр даирәләре берьюлы 144 урамның исемен үзгәртү турында карар чыгардылар.

Ә ике спортчы Кара диңгезне йөзеп чыгарга әзерләнә. Уңыш юлдаш булсын үзләренә!

## Ишетмәсән—, ишет!

Су эзләргә сәләтле кешегә икегә аерылганботаклы чикләвек агачын тотып, аның кеше йогынтысыннан башка хәрәкәтенә игътибар итү дә җитә. Шул юл белән җир астындагы су агымының үткән урынын, киңлеген, якынча тирәнлеген һәм агым юнәлешен билгели. Андый кешеләр шулай ук җир астындагы газ агымын, электр тогы (әгәр шул тәңгәлгә эләксәләр), металл һәм руда «тамыр»ларын да ачыклау мөмкинлегенә ия.

Кайбер эзләнүчеләр тегe яки бу матдәнең тәэсирен тоемлауга үткәрелгән дәвамлы күнегүләрдән соң аерым урында шул матдәнең барлыгын-юклыгын әйтү сәләтен үзләштерә.

Хәзер, билгеле, бу максатта заманча приборлар кулланыла. Ләкин җир астындагы серне приборлар ялгыш күрсәткәндә дә үзенең төгәллеге белән таң калдырган феноменнар бар.

# Иртәгә—Медицина работниклары көне

## Халык шифаханәсе

Норлат разведка бораулавы идарәсе профкомының санаторий-профилакторийда үткәргән чираттагы утырышында катнашучылар төрле халык иде. Алар—биредә дәваланучы НУРБ, НГДУ эшчеләре, колхозчылар, совхоз эшчеләре, сугыш һәм хезмәт ветераннары. Күбесе производстводан аерылгысыз дәваланучылар.

Дәвалау процедураларыннан соң ял бүлмәләрендә тормыш-көнкүреш хакында сөйләшеп киттек. Күпчелек әңгәмәчеләр кибетләрдә товар юклыктан, чиратларның зурлыгыннан зарланып алдылар.

Тик, барлык ял итүчеләрнең дә фикере әлеге шифаханәнең бөтен звеноларында да эшнең яхшы оештырылуы турында иде. Даруга мохтаҗлык заманасында профилакторийда ләм белән дәвалау, төрле үләннәр сыгынтысы ванналары, массаж, физиотерапия кебек дәвалау төрләре үткәрелә.

Озын чиратлар, уч тулы кулланылмаган талоннар тотып бер читтән икенче читкә сугылып йөреп нервлары какшаган кешеләрне күрергә күнегеп беткәнгәдер инде, биредәге тынлык, тәртип безне гаҗәпләндерде. Биредә хезмәт күрсәтүче персоналның игътибарлы, кешеләргә карата ягымлы, сизгер булулары аларга карата ихтирам уята.

Шәфкать туташлары Р. Ботрякова, Ә. Хәсәншина, Г. Афанасьева, ләм белән дәвалаучы М. Галимова һәм башкалар кешеләргә ярдәмгә килергә әзер торалар.

Биредә дәвалау гына түгел, тәмле ризыклар да кешеләрнең күңеленә хуш килә. Поварлар М. Усманова, И. Гайнетдинова пешергән ашлар тәмле, ләззәтле була.

Дәвалау корпусы, тору, азык хәзерләү урыннары шәһәрнең төрле ягында. Ял итүчеләргә дәвалану, ашау-эчү өчен көненә 3 тапкыр автобуста барырга кирәк. Биредә шоферлар Иван Манайрэу, Евгений Додонов бернинди тоткарлыксыз илтеп, алып кайталар кешеләрне.

Биредәге тәртип, чисталык, тынычлык баш врач Нина Ивановна Сапожникованың эшне оста оештыруы турында сөйли. Ул үз эшен яхшы белүче генә түгел, ә культуралы, ягымлы, югары квалификацияле врач та. Аңа биредә диспетчер да, хуҗалык эшләрен белүче дә булырга кирәк. Һәм ул боларның барысын да бик оста башкара.

Аларның барысына да кешеләргә сәламәтлекләрен ныгытуда булышулары өчен зур рәхмәт.

**Х. НӘБИУЛЛИН** һәм тагын 10 имза.

## Сәламәтлек сагында

Бер кем дә, хәтта үзе сау-сәламәт кеше дә тормышында медицина хезмәткәрләренә мөрәҗәгать итми калмый. Безне бит дөньяга китергәндә үк иң элек врач, шәфкать туташы кулына ала. Алар кешенең сәламәтлеген күзәтеп торалар, кирәк булса ярдәм итәләр. Безнең кәефебез аларның талантына, шәфкатьлелегенә бәйле. Менә ни өчен Медицина работниклары көне чын-чынлап халык бәйрәме дә.

Традиция буенча безнең илебездә ул бәйрәм июньнең өченче якшәмбесендә билгеләп үтелә. Кызыл Хач җәмгыяте сәламәтлек саклау органнарына мөһим һәм бик кирәкле эшләрендә һәрчак ярдәмгә килә. Еллар үтү белән сәламәтлек саклау органнары арасында үзара мөнәсәбәт киңәйде, эшлекле элемтәләр ныгыды. Һәм бүген дә Кызыл Хач җәмгыяте активистлары сәламәтлек вахтасында уяу торалар. Аларның эчкерсез хезмәте һәркем күз алдында. Әнә шикәр заводы врач-терапевты З. М. Әмирова, фельдшеры Л. И. Прокофьева, медицина пункты фельдшеры Е. М. Стручкова, НГДУ сәламәтлек пункты врачы М. С. Родионов, поликлиника службасы врач-терапевты В. Г. Семенова һәм тагын бик күпләр, үзләренең төп эшләрен җәмәгать эшләре белән бергә бәйләп алып баралар.

Авыллардагы медицина хезмәткәрләренең эше аеруча мактауга лаек. Алар бит кыен шартларда, хәзерге даруларга кытлык заманында да, авыл халкына һәртөрле медицина ярдәме күрсәтергә тырышалар. Чулпан медпункты фельдшеры, Кызыл Хач җәмгыятенең участок комитеты (учком) председателе Р.С. Ханиева, Иске Чаллы участок больницасы медицина работнигы, учком председателе Т. А. Нилова, Т. М. Кәлимуллина (Мамык участок больницасының яшь белгече), Р. А. Кадыйров (Фома), В. Г. Сашина (Тимерлек), Л. М. Егорова (Елаур), З. И. Зарипова (Кычытканлы) һәм башка бик күп авыл медицина пунктлары хезмәткәрләре халык бәхете, аларның сәламәтлеге сагында һәрчак уяу торалар.

Бүген безнең иң шәфкатьле кешеләребез—кеше тормышын саклап калуда каннарын кызганмаган донорлар турында да җылы сүзләр әйтәсе килә. Район үзәк больницасының баш шәфкать туташы М. И. Гостева, Түбән Чаллы медпунктының элеккеге акушеркасы, хәзер пенсиядәге, СССРның мактаулы доноры В. Б. Власова, Яңа Әмзә фельдшерлык пунктыннан, СССРның мактаулы донорына кандидат Г. Сәйфетдинова, район үзәк больницасы баш врачы З. А. Шабаев, врач-гинеколог С. В. Ильина, хатын-кызлар консультациясе акушеркасы Л. Н. Емельянова һәм башкалар әнә шундыйлар. Алар тәүлекнең теләсә кайсы мизгелендә кешеләргә ярдәмгә килергә әзер торалар. Түләүсез кан бирү буенча бригаданың яшь члены Светлана Кувшинова, кан алу пункты хезмәткәрләре З. Галкина, Г. Аюпова, Кызыл Хач җәмгыятенең шәфкать туташы Х. Җаббарова, шәфкать туташы А. Хәбибуллина үз эшләрен сөеп башкаралар.

Мәрхәмәтле ак халатлылар турында бик күп сөйләп булыр иде. Аларның һәркайсы үзенә тормышка юл сайлаганда кеше турында кайгырту, аны үлемнән коткарып калуның нинди изге эш икәнен аңлаганнардыр, мөгаен. Әйдәгез, бүген медицина работниклары көнендә аларга нык сәламәтлек, изге эшләрендә уңышлар телик.

**В. БАТРАКОВА,**
Кызыл Хач җәмгыятенең район комитеты председателе.



**Лаборатор юл белән тикшерүләр санэпидстанция эшчәнлегендә зур урын алып тора. Фәнгә нигезләнгән бу ысул санитар-гигиеник тикшерүләрне тирәнтен, зур төгәллек белән башкарырга мөмкинлек бирә.**

**Октябрь районының бактериологик лабораториясе санэпидстанциянең башка бүлекләре белән беррәттән тышкы тирәлекнең санитар торышын яхшырту һәм авыру очракларын киметү максатында эш алып бара. Бу лабораториягә йомышы төшмәгән кешене районда табып та булмыйдыр, мөгаен.**

**Мәстүрә Әгъзам кызы Мостафина һәм Зөһрә Назыйм кызы Ханбикова әлеге лабораториядә күп еллар дәвамында эшлиләр. Ясала торган анализга алар зур җаваплылык белән карыйлар, һәрбер күрсәткечнең кеше сәламәтлеге, ә кайчакта хәтта гомере өчен зур әһәмияткә ия булганын аңлап, төгәллек белән башкарырга тырышалар. Тыйнак һәм эшчән бу ике ханым коллективның да, район халкының да ихтирамын казандылар.**

**Рәсемдә: лаборантлар М. Ә. Мостафина (сулда) һәм З. Н. Ханбикова (уңда).**

**Н. Азизов фотосы.**

## Мин аларга бурычлы

70 ел гомердә минем башымнан күп хәсрәтләр, борчылулар узды. Шуңа да тормышның бәясен яхшы беләм. Быелның апрелендә үземне бик начар хис иттем һәм күршемдәге врач Гатифә Габдулхаковна Галиевага мөрәҗәгать иттем. Рәхмәт аңа. Ул күршеләренә ярдәмнән баш тартмый: киңәшләрен бирә, кирәк булса шунда ук профессиональ ярдәм дә күрсәтә. Врач бу юлы да мине караганнан соң, сәламәтлегемнең куркыныч астындалыгын күреп, шунда ук «Ашыгыч ярдәм» машинасын чакыртты. Әнә шулай мин район үзәк больницасы стационарының терапия бүлегенә эләктем. Анда минем хәлем начарланган: аңымны җуйганмын, тормышым кыл өстендә булган. Галина Яковлевна Калентьева, бүлек мөдире Галина Евгеньевна Фомина минем тормышым өчен көрәшкәннәр. Шөкер, мин хәзер исән.

Врач Галина Яковлевна Калентьеваның авыруларга карата игътибарлы булуы, шәфкать туташлары Р. Хәйруллина, Р. Бикчурова һәм башкаларның мәрхәмәтлеге һәркемгә яшәүгә көч бирә. Мин терапия бүлеге хезмәткәрләренә тормышымны саклап калганнары өчен зур бурычлы. Аларга эшләрендә уңышлар, сәламәтлек телисе килә.

**А. КОРАБЛЕВА.**
Норлат шәһәре.

## Шәфкать туташы

**Шәфкать туташы Хәдичә Мортаза кызы Салихованың фидакарьлегенә багышлыйм.**

**Хәдичә апа иртүк эшкә бара,**
**Иңнәрендә аның ак халат.**
**Иңендәге ак халаты кебек**
**Күңеле дә аның изге-ак.**

**Инде әйтмәсәм дә белгәнсездер,**
**Хәдичә апа—шәфкать туташы.**
**Бу тормышта шәфкать туташлары,**
**Бар да аның кебек булсачы.**

**Әгәр берәр каты авыру булса,**
**Төннәрен дә аңа киләбез.**
**Беркайчан да кире какмый торган**
**Олы җанлылыгын беләбез.**

**Әнә газаплана яшь-яшь ана,**
**Уйнап йөри нәни баласы,**
**Анасына бер-бер хәл булмасмы?**
**Шул сабые ятим калмасмы?**

**Шул чакларда шәфкать туташыбыз**
**Табиб түгел, тормыш терәге.**
**Җанга җылы сүзе, эше белән,**
**Уята ул яшәү теләге.**

**Мәрхәмәтле шушы олы җанга,**
**Хөрмәт белән башны иябез,**
**«Игелегең игелек булып кайтсын,**
**Бәхетле бул берүк»,—диябез.**

**Р. МӘСЛӘХОВА,**
**Киекле авылы.**

## Бәхет телик аларга

Район үзәк шифаханәсе стационарының терапия бүлегендә авырулар күп була. Бүлек мөдире Галина Евгеньевна Фомина, дәвалаучы врач Роза Мөбиновна Фәхриева, өлкән шәфкать туташы Татьяна Алексеевна Семенова иптәшләргә биредә эш аеруча күп. Әлеге бүлеккә кешеләр төрле авырулар белән дәваланырга киләләр. Шәфкать туташлары Р. Хәйруллина, Р. Сөнгатуллина, М. Курникова, Ф. Әхмәтова, Г. Сибгатова, С. Парфенова һәм башкалар авыруларга игътибарлы, кешеләрнең сәламәтлекләре өчен кулларыннан килгәннең барысын да эшләргә әзер торалар.

Мин үзем Фома авылыннан. Миңа авыру сәбәпле әлеге бүлектә еш дәваланырга туры килә. Шуңа да биредәге персоналның кешеләр сәламәтлеге турында нинди кайгыртучанлык күрүләрен яхшы беләм һәм аны үзем кичерергә туры килә. Аларның яхшылыгын күп күрдем. Шуңа да врачларга, шәфкать туташларына эштә уңышлар, бәхет телисем килә. Бер минем фикерем генә түгел бу, ә биредә дәваланырга туры килгән һәр авыруның теләге.

**Ф. КАҢЯФИНА.**
Фома авылы.

## Футбол күзәтү

# Әлмәтлеләрне җиңде

Татарстан беренчелегенә үз группасындагы чираттагы уенны «Факел» Әлмәт шәһәрендә үткәреп кайтты. Анда команда җирле «Электрон» белән очрашты.

Команда начальнигы Григорий Шугаев очрашуны болай бәяләде:

«Уен катлаулы шартларда барды. Соңгы көннәрдә булып үткән яңгырлардан мәйдан кибеп тә өлгермәгән, уртасында бәләкәй генә күл дә бар иде. Бу еш кына уенчыларның исәп-хисапларын буташтырды.

Факеллылар, кунакта булуларына карамастан, актив уйнадылар, инициативаны кулдан ычкындырмадылар. Гера Пальченконың ерак дистанциядән типкән бер тубы көндәшләребез капкасына керде һәм безгә җиңү китерде».

Бүгенге көндә «Факел»ның 6 уенынан 8 очкосы бар. ТССР беренчелегенә беренче группа командалары арасында ул дүртенче урынны били. Хәер, РСФСР беренчелегенә зона ярышларында да нәкъ шул ук дүртенче урында. Бу группада, алда хәбәр ителгәнчә, команданың 8 уенынан 10 очкосы бар.

**Р. АЙЗАТУЛЛИН.**



# Шәһәрне макта, авылда тор

дигән әйтем бар халыкта. Чынлап та соңгы вакытта шәһәрдән авылга күчәргә теләүчеләр еш очрый башлады. Әмма аларның күбесенең бу теләге һаман да хыялда гына кала килә. Чөнки бераүләрне күченү белән бәйле акча чыгымнары куркытса, икенчеләре үзләренең күчеленә ошаган төбәкне һәм белгечлекләре буенча хезмәт урыны табалмаудан гаҗиз.

Әлеге кешеләргә ярдәм йөзеннән СССР Министрлар Советы 1973 елның 31 маенда ук инде «Күченү буенча льготалар турында» карар чыгарган иде. Анда авыл җиренә эшкә һәм яшәү өчен күчәргә теләүчеләр, аларның гаилә әгъзаларына кагылышлы льготалар каралган. Әлеге карарга моннан соң да (1988 елның 5 августында, 1989 елның 5 апрелендә, 1990 елның 12 апрелендә) Министрлар Советы тарафыннан өстәмәләр һәм төзәтмәләр кертелде.

Карарда әйтелгәнчә, автономияле республика, край, өлкә һәм административ район эчендә колхозларга, совхозларга һәм башка авыл хуҗалыгы предприятиеләре һәм оешмаларына күченүче гаиләләргә юл чыгымнары, 2 тонна җиһазны һәм мал-туарларны күчергән өчен түләнә. Моннан тыш шәхси хуҗалыкны торгызып җибәрү өчен гаилә башлыгына 2000 мең сум һәм гаиләнең һәр әгъзасына 500 сум исәбеннән дәүләт казнасыннан бер тапкыр акчалата ярдәм күрсәтелә.

Хөкүмәт карарларында күченүчеләрне торак төзү материаллары, терлек-туар белән тәэмин итү тәртибе дә күрсәтелгән. Мәсәлән, совхозлар күчкән гаиләләрне ел дәвамында аерым торак йорт яки фатир белән тәэмин итәргә, билгеләнгән зурлыкта йорт яны участоклары бирергә тиеш. Күченгәннән соң ике ел үтүгә хуҗалар фатир өчен түләүдән азат ителергә тиешләр. Шушы ук чорда аларга бушлай ягулык бирелә һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтелә.

Совхозлар шулай ук күченгән гаиләләргә үз терлек-туарын булдыруда ярдәм итәргә тиешләр. Бу исә арзанрак бәягә терлекләр сатып бирү, мал азыгы белән тәэмин итү һәм хуҗалыкның мөмкинлегенә карап сыер, сарык, дуңгыз баласын хәтта бушлай бирүдән гыйбарәт. Югарыда санап үтелгән өстенлекләр—күченүчеләргә тудырылган шартларның иң күренеклеләре. Болардан тыш та билгеләнгән льготалар шактый. Әгәр бу хакта тагын да нечкәләбрәк белешәсегез килсә, җомга көннәрендә иртән сәгать 9 дан кичке сәгать 5 кә кадәр түбәндәге адрес буенча мөрәҗәгать итә аласыз: Норлат шәһәре, Совет урамы, 138 йорт, 9 нчы кабинет.

**А. ИШМУЛИН.**

«Юридик ярдәм үзәге» кооперативының консультанты.






**Салдакай авылында яшәүче сөекле әниебез Минзифа Мортазинага 60 яшь тула, 9 бала үстергән кадерле әниебезне туган көне белән котлап, аңа сәламәтлек, гаилә иминлеге, без—балаларының игелеген күреп озак еллар әтиебез белән тигез яшәвен телибез.е**

**Балалары, киленнәре, кияүләре, оныклары.**

# Ярминкә һәм сабан туе

**ТРАДИЦИОН ЯРМИНКӘ**

**Быел ярминкә башка еллардагыдан үзенчәлеклерәк. Ул 15 июньдә аэропорт мәйданында иртәнге сәгать 6 да башлана.**

**Анда Октябрь райпосының барлык сәүдә предприятиеләре, НГДУ, ОРСы, тимер юл, урман хуҗалыгы промышленносте ОРСлары, Кошки, Чаллы Башы районнары сәүдә предприятиеләре катнаша.**

**10.00 сәгатьтә Октябрь райпосы халык соравы зур булган товарлар сату буенча аукцион.**

**11.00. Кулинария әйберләре (җәмәгать туклануы предприятиесе үткәрә) сату буенча аукцион.**

**12.00 «Норлатнефть НГДУсы ОРСы аукционы.**

**13.00. Тимер юл ОРСы аукционы.**

**14.00. Урман промышленносте хуҗалыгы аукционы.**

**МИЛЛИ БӘЙРӘМ—САБАН ТУЙ**

**Ул 16 июньдә аэропорт мәйданында уза.**

**8.00. Сабан туй турында информация һәм бәйрәм программасы.**

**9.00 Бәйрәмне ачу.**

**9.05. Атлар нарады.**

**9.35—13.00. Атлы-спорт ярышы.**

**10.00 Казан шәһәренең ДОСААФ яшь парашютчылар мәктәбе чыгышы.**

**13.00. Милли көрәш.**

**10.00. КУЛЬТУРА ПРОГРАММАСЫ:**

**—видеосалон;**

**—карусель;**

**—үзешчән артистлар чыгышы;**

**—тынлы оркестр чыгышы.**

**11.00 СПОРТ-МАВЫКТЫРГЫЧ ПРОГРАММАСЫ.**

**Сатириклар һәм мәзәк аттарцион һәм конкурсларда катнашучылар белән вокаль-инструменталь ансамбль чыгышы.**

**КОНКУРСЛАР:**

**—шешәдән сөт имүчеләр;**

**—уенчык төрү;**

**—капчык киеп йөгерү;**

**—сулы чиләкләр күтәреп йөгерү;**

**—авызга кашык, йомырка кабып йөгерү;**

**—канат тарту;**

**—уенчык кисү;**

**—чүлмәк вату;**

**—мәргәннәр;**

**—бәйләнгән күзләр белән капчык сугышы;**

**—гер күтәрү;**

**—ату ярышлары;**

**—бүрәнә өстендә йөрү буенча ярыш;**

**—капчыклар белән көрәш (бум);**

**—колгага әтәч алырга менү.**

**АТ ЧАБЫШЛАРЫН ТАМАША КЫЛУ**

**Уенга катнашырга теләүче ат чабышларын яратучылар, программа, атлар, аларның узган елгы нәтиҗәләре белән танышып, бер атка бәя куялар. Әгәр бәя куелган ат отса, отыш акчасы шуңа бирелә. Билет бәясе 3 сум.**

**Отышка түләүләр судья комиссиясе чираттагы чабышта җиңгән ат турында белдергәннән соң әлеге атка дип алган билет буенча (махсус кассадан) үткәрелә.**

**Барлык чыгышлар тәмамлангач ат-спорт ярышында иң яхшы вакытны күрсәткән 8 аттан абсолют җиңүчене билгеләү өчен группа аерып алына.**

**Кошкиның 57 нче профессиональ-техник училищесы (база предприятиесе «Самараагрострой») 3—4 разрядлы квалификациягә ия булган эшчеләр хәзерләү өчен 1991—1992 уку елына түбәндәге белгечлекләр буенча укырга чакыра (уку срогы бер елдан 3 елга кадәр):**

**1. Электр ярдәмендә кулдан эретеп ябыштыручы.**

**2. Ташчы, корыч һәм тимер-бетон корылмаларны монтажлау буенча монтажчы-электр ярдәмендә эретеп ябыштыручы.**

**3. Буяучы (төзүче-штукатур).**

**4. Автомобильләр ремонтлау буенча слесарь.**

**5. Төзелеш объектларын плитә белән тышлаучы, мозаика белән бизәп тышлаучы.**

**6. Төзелеш эшләре башкару өчен балта остасы.**

**7. Слесарь-сантехник, газ ярдәмендә эретеп ябыштыручы.**

**8. Май-сыр ясаучы.**

**Яше 15 тән дә ким булмаган егетләр һәм кызлар кабул ителә. Уку чорында укучылар көненә 4 тапкыр ашау, кием-салым, тулай торак, практика вакытындагы эш хакының 50 проценты күләмендә стипендия белән тәэмин ителәләр. Училищеның укыту-производство мастерскойлары, ашханәсе һәм спорт залы булган уку корпусы, заманча уку кабинетлары, уңайлыклары булган 3 катлы тулай торагы, спорт комплексы һәм стадионы бар. Спорт секцияләре, үзешчән сәнгать, фәннәр буенча, техник иҗат түгәрәкләре даими эшли. Училищены бик яхшы билгесенә тәмамлаучылар югары уку йортларына конкурстан тыш керү хокукыннан файдаланалар, шулай ук профессиональ-техник әзерлек буенча техникумнарга һәм югары уку йортларына җибәреләләр.**

**Училище югарыда күрсәтелгән профессияләргә өйрәтү өчен укучыларны колхоз-совхоз һәм башка оешмаларның юлламасы буенча да кабул итә. Укуны тәмамлаучылар эшкә юллама биргән оешмага җибәреләләр.**

**Училищега кергәндә түбәндәге документлар кирәк: белем турында таныклык, туу турында таныклык, яшәү урыныннан һәм гаилә хәле турында белешмә, 286 нчы формалы медицина белешмәсе, 3х4 зурлыкта дүрт фоторәсем. Паспорт һәм хәрби билет укырга килүченең үз кулында булырга тиеш. Кабул итү комиссиясе якшәмбедән кала һәр көнне эшли.**

**Безнең адрес: Самара өлкәсе, Кошки авылы, 4 нче квартал, 2 йорт, 57 нче ПТУ. Поезд белән Погрузная тимер юл станциясенә кадәр барырга.**

**Телефоннар: 2—20—32, 2—22—84, 2—23—65 (тулай торак).**

**х х х**

**Күптармаклы производство предприятиесенә чистарту корылмасына сакчылар һәм слесарлар кирәк.**

**Хезмәткә түләү штат расписаниесе буенча.**

**МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.**

**Учредительләр халык депутатларының Октябрь район Советы, КПССның партия оешмасы.**

**Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.**

**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.**
**ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.**

**Газетаны Нурзия ФӘСХЕТДИНОВА җыйды. АСИЯ МОРАТХАНОВА верстка ясады. Фирдания ХУҖИӘХМӘТОВА басты. Корректор—Рәзинә ШӘЙХУЛЛИНА.**

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак. Зказ 71. Тираж 3415.